РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«23» гыйнвар 2026ел

№ 4

2026 елда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә элемтә линияләре һәм корылмаларының сакланышын тәэмин итү турында

Тотрыклы элемтә эшчәнлеген тәэмин итү, элемтәнең җир асты коммуникацияләрендә аварияләрне кисәтү һәм 1995 елның 9 июнендәге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 578 номерлы карары белән расланган, Россия Федерациясенең элемтә линияләре һәм корылмаларын саклау кагыйдәләре таләпләрен үтәү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2000 елның 22 маендагы 363 номерлы карары «Торба үткәргеч транспортында, электр тапшыру һәм элемтәнең кабельле, һава линияләрендә аварияләрне кисәтү, энергетика объектларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү чаралары турында» карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан барлык милек формасындагы предприятиеләр, оешмалар җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән эш башкару ордеры булмаган очракта, юридик яки физик затка караган җир участогында, 0,3 м тирәнлектә сөрүдән тыш, элемтә линияләре саклау зонасында җирне ачып эш башкаруны тыю, һәм бу эшләрне җир асты инженер-коммуникация корылмалары, шулай ук җир участоклары хуҗалары булган кызыксынган оешмалар белән килештерү. Каршылыклар яки бәхәсләр килеп чыкканда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 9 июнендәге № 578 «Россия Федерациясенең элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» карарына таянырга;

- җир эшләрен килештерү һәм башкару өчен җаваплы затларны билгеләү өчен җирле актлар белән, җир эшләрен башкару тәртибен билгеләү, элемтә кабельләре саклау зонасында җир эшләре башкарганда җаваплы затларны билгеләү, саклау-профилактика эшләрен башкару өчен кирәкле мәгълүматлар бирү (җир казу техникасы булу, элемтә кабельләре үтү районнарында эш планнары, механизаторлар һәм инженер-техник хезмәткәрләр исемлекләре).

2. Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан милек төренә бәйсез рәвештә предприятиеләргә, оешмаларга һәм физик затларга:

- элемтә коммуникацияләренең сакланышын тәэмин итү эшләрен башкаруда элемтә предприятиеләренә ярдәм күрсәтү;

- элемтә предприятиесенең беренче таләбе буенча элемтә коммуникацияләренә куркыныч тудыручы сәбәпләр бетерелгәнче барлык эшләрне туктатырга.

3. Элемтә предприятиеләренә гамәлдәге законнар нигезендә кабель линияләре һәм корылмаларның саклау зоналарын билгеләү эшен дәвам итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы рәсми сайтында (https://tulachi.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Б.М. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин